ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ВЕТЕРИНАРИИ
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР
КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ
ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.06.2024 Казан шәһ. № 51-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 февралендәге 132 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын һәм вазыйфаи затларын дәүләт серенә кертү кагыйдәләре нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада китерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе
җитәкчесе А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсенең
2024 елның 19 июнендәге
51-од номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Бухгалтерлык исәбе, хисабы, икътисадый планлаштыру һәм дәүләт заказы бүлеге җитәкчесе;
2. Кадрлар һәм дәүләт эше бүлеге җитәкчесе;
3. Хокук бүлеге җитәкчесе;
4. Терлекләрнең йогышлы авырулары һәм эпизоотиягә каршы чараларны оештыру бүлеге җитәкчесе;
5. Дәвалау-профилактика чаралары бүлеге җитәкчесе;
6. Ветеринария иминлеген тәемин итү, ветеринария-санитария экспертизасы һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге җитәкчесе;
7. Контроль-ревизия эше бүлеге җитәкчесе;
8. Ветеринария эшен оештыру бүлеге җитәкчесе;
9. Цифрлаштыру һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы секторы җитәкчесе;
10. Мобилизация эше, граждан оборонасы һәм яшеренлек режимын тәэмин итү буенча әйдәүче киңәшче.